**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 29 сентябрь № 725

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 ел, 2 ноябрь, ТРЗ-73 нче Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы вазыйфалар биләүче хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү системасын камилләштерү турында» 2013 ел, 26 сентябрь, ПУ-943 нче Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 303 нче, 2013 ел, 20 август, 585 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның икенче абзацында «29» һәм «149,2» саннарын шул ук эзлеклелектә «26» һәм «136,96» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турындагы нигезләмәдә:

1 бүлекнең 1.6 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Урнашу урыны (юридик адрес): 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт»;

3.2 нче пунктның егерме беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән — физкультура һәм спорт өлкәсендә идарә итү вазыйфасын башкарганда (04.04*)»;

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа егерменче – егерме икенче абзацлар өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасы нигезендә, үзенең компетенциясе чикләрендә матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру»;

«гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә үзенең компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча телдән һәм язмача формада хокукый консультация бирү рәвешендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү»;

«федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә социаль ярдәм күрсәтүгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү һәм судларда, дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда граждан мәнфәгатьләрендә эш итү»;

3.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Агентлык заказчылар – «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» һәм «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү вазыйфаларын башкаруга вәкаләтле орган булып тора, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен заказны үзәкләштереп урнаштыруны оештыру мәсьәләләре турында» 2008 ел, 28 август, 615 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен үзәкләштереп сатып алына торган товарларның, заказ бирелә торган эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең детальләштерелгән исемлеге нигезендәге товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрдән тыш.

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына законнар нигезендә әлеге карарның 1 нче пунктын гамәлгә ашыруны тәэмин итүче оештыру карарлары кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карары белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2013 ел, 20 август, 585 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\725.docx